**СОВЕТ НИКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422627 с. Никольское,
ул. Центральная, д.35
тел: 4-31-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКОЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422627 Никольский авылы,
Үзәк урамы, 35 нчы йорт,
тел: 4-31-44

**2023елның 27 ноябре** **65 номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022елның 6 декабрендәге 66 номерлы Никольский авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023елның 04 августындагы 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге Советы **карар чыгарды**:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022елның 6 декабрендәге 66 номерлы Никольский авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

**1) 18 статьяның 2 пунктының беренче абзацында сүзләрен:**

- " программаны раслаган муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актына ярашлы рәвештә” сүзләрен " "Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе субъектының югары башкарма органы, муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе тарафыннан билгеләнгән дәүләт (муниципаль) программалары исемлеге һәм структурасы нигезендә"дигән сүзләр белән алыштырырга;

**2) 17 статьяның 1 пунктында:**

- "һәм аларның структур элементлары" сүзләрен алып ташларга;

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Никольский**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **А.Н.Пашагин**